Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Урман-Кәләй авыл Советы

КАРАРЫ

20 февраль 2026 ел № 13

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 168 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Урман-Кәләй авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Урман-Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31, 32 бүлекләре нигезендә,

Урман-Кәләй авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 168 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Урман-Кәләй авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл Советының 2015 елның 5 маендагы 198 номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 7 номерлы, 2018 елның 20 августындагы 103 номерлы, 2019 елның 6 мендагы 141 номерлы, 2021 елның 2 августындагы 20 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4.1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»;

1.2. 3 пунктның 3.1, 3.2 пунтчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затлар (мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);

3.2. мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрге балалар, әлеге пунктның 3.1 бүлегендә күрсәтелгән физик затлар;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында, Урман-Кәләй авылы, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтындана урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Урман-Кәләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев